# Башлангыч мәктәптә дәресләрне оештыруда **эшчәнлекле якын килү**



**Заһретдинова Н.М., Петрунина Н.Р., Шәфыйкова Г.Ш.**

Түбән Кама шәһәре Бакый Урманче исемендәге 2 гимназиянең югары категорияле башлангыч сыйныф укытучылары

# ЭШЧӘНЛЕК



БАРЛЫК БИРЕМНӘРНЕ ДӘ ТЕЛӘП ЭШЛИМ

# Нәрсә ул эшчәнлекле метод



Балага белемне әзер килеш биреп түгел, аңа уку, танып-белү эшчәнлегендә  белемнәрне үзләштерергә ярдәм итеп укыту методы эшчәнлекле метод дип атала.



*Чын укытучы укучысына мең еллар хезмәт көче куелган әзер бинаны күрсәтми, ә төзелеш материалын эшкәртүгә юнәлеш бирә, аның белән бергә бинаны төзи һәм төзергә өйрәтә.*

*Адольф Дистервег*

# Эшчәнлекле укыту технологиясе

Укытучының төп бурычы – баланы эшчәнлеккә тартучы шартлар тудыру.

*Людмила Георгиевна Петерсон*



Эшчәнлекле метод технологиясенең база нигезе

Яңа белем ачу дәресе

# Яңа белем ачу дәресе этаплары

I. Уку эшчәнлегенә мотивация тудыру.

✔ *уку эшчәнлегенә караган таләпләр актуальләштерелә (“кирәк”).*



✔ *уку эшчәнлегенә кереп китү теләге уяту өчен шартлар тудырыла (“телим”).*

✔ *тематик рамкалар куела (“булдырам”).*

# Яңа белем ачу дәресе этаплары

II. Белемнәрне актуальләштерү һәм эшләп карау вакытында авыр урыннарны билгеләү.

- ✔ укучылар яңа биремнәр үтәр өчен белемнәрнең җитеп бетмәвен ачыклый, проблеманы хәл итүнең үз вариантларын тәкъдим итә.





# Яңа белем ачу дәресе этаплары

III. Авыр очракның урынын һәм сәбәбен билгеләү.

- ✔ *укучы моңа кадәр башкарган гамәлләрен вербаль чаралар һәм шартлы тамгалар ярдәмендә торгыза (“авырлык кайчан һәм кайда туды – әйтеп күрсәт”);*
- ✔ *үзенең гамәлләрен элек кулланган гамәлләре*



*белән чагыштыра, нәкъ менә шушы типтагы биремнәрне үтәр өчен нинди белем һәм күнекмәләр җитмәвен әйтеп бирә.*

# Яңа белем ачу дәресе этаплары

IV. Авырлыктан чыгуның проектын төзү.

- ✔ *үзара аралашу процессында укучылар уку эшчәнлегенең проектын төзиләр: максат куялар, эшнең темасын хәл итәләр, эшчәнлек ысулын сайлыйлар, максатка ирешүнең планын*



*төзиләр, нинди чаралар һәм ресурслар кулланачакларын, вакытны билгелиләр.*

# Яңа белем ачу дәресе этаплары

V. Проектны тормышка ашыру.

- ✔ *Укучылар фаразлар чыгаралар, беренчел проблемалы ситуациядән чыгу юлының моделен төзиләр.*
- ✔ *Укучылар тәкъдим иткән төрле вариантлар бергәләп тикшерелә, уңышлысы сайлап алына. Бу вариант вербаль чаралар һәм тамгалар ярдәмендә ныгытыла.*
- ✔ *Проблемалы ситуация бергәләп сайлап алынган ысул ярдәмендә чишелә. Соңыннан яңа белемнең гомуми билгеләре тәгаенләнә, проблеманы хәл итү ысулы истә калдырыла.*

# Яңа белем ачу дәресе этаплары

VI. Әйтеп эшләп, беренчел ныгыту.

- ✔ *Коммуникатив эшчәнлек формасында (парларда, төркемнәрдә, бергәләп) яңа эшчәнлек ысулына караган типик биремнәрне башкаралар, чишү ысулларын бер-берсенә сөйлиләр.*






# Яңа белем ачу дәресе этаплары

VII. Эталон буенча үз-үзеңне тикшерү элементы белән мөстәкыйль эшләү.

- *Индивидуаль эш оештырыла: яңа типтагы биремнәр мөстәкыйль эшләнә, белемнәр эталон ярдәмендә үзлектән тикшерелә, укучылар хаталарын ачыклыйлар, төзәтәләр.*




*Авырлык туган урыннар билгеләнә, хаталарны кисәтү юллары тәгаенләнә. Укытучының максаты – һәр укучы эшчәнлегендә уңыш ситауциясе тудыру.*

# Яңа белем ачу дәресе этаплары

VIII. Яңа белемнәрне үзләштерелгән белем системасына кушу һәм кабатлау.

- ✔ *Яңа белемнәрне куллану чикләре ачыклана, ярым иҗади биремнәр башкарыла.*



*Нәтиҗәдә өйрәнелгән нормалар буенча аң эшчәнлеге автоматлаштырыла һәм алда өйрәнеләчәк яңа материалга җирлек тудырыла.*

# Яңа белем ачу дәресе этаплары

IX. Дәрестә уку эшчәнлегенә рефлексия.

- ✔ *Дәрестә өйрәнелгән яңа эчтәлек ныгытыла, билгеләп куела, укучы үз эшчәнлеген бәяли, рефлексия оештырыла.*
- ✔ *Максат нәтиҗә белән чагыштырыла, туры килү дәрәҗәсе ачыклана, алдагы дәрескә максат куела.*





# Яңа белем ачу дәресе этаплары

IX. Дәрестә уку эшчәнлегенә рефлексия.

*Әлеге этапта куелачак сораулар:*

- *Нәрсәгә өйрәндек?*
- *Нинди яңалык белдек?*
- *Нинди ысуллар белән өйрәндек?*
- *Белемнәрне кайларда кулландык?*
- *Тагын кайларда кулланырга мөмкин?*
- *Яңа ситуация алдагысыннан ничек аерыла?*
- *Авырлык кайда очрады?*
- *Сыйныфның (синең) эш нәтиҗәсе нинди?*
- *Кемне мактый алабыз?*
- *Тагын нәрсә буенча әле эшләргә кирәк?)*

# “Үсеш баскычы”



# Технологиянең нәтиҗәлелеге нидән гыйбарәт?

*Укучы әзер белемне кабул итүче түгел, аны эзләп алучы буларак карала. Ул уку эшчәнлегенең формасын да, эчтәлеген дә аның нормалар системасын да аңлап кабул итә, үз эшчәнлеген камилләштерүдә катнаша.*

*Технология укучыда универсаль уку гамәлләрен һәм гомуммәдәни күнекмәләрне уңышлы формалаштырырга ярдәм итә.*



# Технологиянең нәтиҗәлелеге нидән гыйбарәт?


- *Эзлеклелек һәм дәвамчанлык принцибы балаларның яшь һәм психологик үзенчәлекләрен истә тоткан технология, эчтәлек һәм методикалар дәрәҗәсендә тәкъдим ителә.*
- *Укучыларда дөнья (табигать, җәмгыять, үзе турында, социомәдәни дөнья, эшчәнлек дөньясы, фәннең башка фәннәр арасындагы урыны) турында гомуми күзаллау формалаша.*





# Технологиянең нәтиҗәлелеге нидән гыйбарәт?

*Белем бирү процессында стресс тудыручы барлык факторлар да юкка чыгарыла, мәктәптә һәм дәресләрдә үзара диалогка корылган дустанә мохит тудырыла.*





*Сайлап алу ситуациясендә укучыларда, проблемалы ситуациядән чыгуның төрле вариантларын карап чыгып, адекват карар кабул итә белү күнекмәсе формалаша.*

# Технологиянең нәтиҗәлелеге нидән гыйбарәт?



*Белем бирү процессында иҗади башлангычка, укучылар тарафыннан иҗади эшчәнлек тәҗрибәсе туплануга максималь юнәлеш бирелә.*

# Технология нинди мөмкинлекләр бирә?

- ✔ *Уку процессын кызыклы һәм иҗади итә;*
- ✔ *Теләсә кайсы предметны өйрәнгәндә кулланыла ала;*
- ✔ *Уку эшчәнлеген оештыруда балага сайлап алу мөмкинлеге бирә;*
- ✔ *Төрле дәрәҗәдәге белем бирүгә уңайлы шартлар тудыра;*



- ✔ *Төшенчәләр үзләштерүнең барлык кирәкле этапларын үтәргә мөмкинлек бирә;*
- ✔ *Баланың укуга кызыксынуын үстерә, иҗатка күнектерә, мөстәкыйль шәхес формалаштыруга ярдәм итә.*

Эшчәнлегегез матур нәтиҗәләргә китерсен өчен, эзләнергә, кыю атларга кирәк!

**Игътибарыгыз өчен рәхмәт!**